Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

13 май 2020 ел №374

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, муниципаль мөлкәтне һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү (азат итү) шартлары турында

«Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 01 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 401 статьясының 3 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге «Россия икътисады тармакларының яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәлнең начараюы шартларында зыян күрүчеләрнең исемлеген раслау турында»гы 434 нче номерлы, 2020 елның 3 апрелендәге «Күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартларына һәм срокларына таләпләр билгеләү турында»гы 439 нчы номерлы карарлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 314 нче номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 820-р, 821-р номерлы боерыклары нигезендә,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, Әлмәт районының муниципаль казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләреннән азат итү шартларын расларга (1 нче кушымта).

2. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, Әлмәт районының муниципаль казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен кичектереп тору өчен кушымтада бирелгән шартларны расларга (2 нче кушымта).

3. Әлмәт районы муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен кичектереп тору өчен беркетелгән шартларны расларга (3 нче кушымта).

4. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге «Россия икътисады тармакларының яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәлнең начараюы шартларында зыян күрүчеләрнең исемлеген раслау турында» 434 нче номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгәндә, Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетына әлеге карарга үзгәрешләр кертмичә генә эш алып барырга һәм кулланырга.

5. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының икътисадый

үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Закиров Ш.К.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль
районы Советының 2020 елның
13 маендагы 374 нче номерлы
карарына 1 нче кушымта

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын
Әлмәт районының муниципаль казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләреннән азат итү шартлары

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты исеменнән эш итүче Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына Әлмәт муниципаль милкендәге муниципаль мөлкәтне (алга таба - муниципаль мөлкәт) арендалау шартнамәләре буенча түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а ) арендаторлар- кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мөрәҗәгатеннән соң җиде эш көне эчендә, авиапассажирлар йөртү өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән, аэропорт эшчәнлеге, автопассажирлар йөртү, мәдәният, ял һәм күңел ачу, физкультура-савыктыру эшчәнлеге һәм спорт, туристлык хезмәтләре, кунакханә бизнесы, җәмәгать туклануы, дәүләтнеке булмаган өстәмә белем бирү учреждениеләре, күргәзмәләр конференцияләр оештыру, халыкка көнкүреш хезмәтләре күрсәтү (ремонт, химчистка, чәчтарашханә һәм матурлык салоннары) эшчәнлеге, азык-төлек булмаган товарларны ваклап сату өлкәсендә эшчәнлек алып баручы (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) арендаторлар белән, Әлмәт районының муниципаль казнасын тәшкил итүче, 2020 елның апрель - июнь айларында дәүләт милке чикләнмәгән җирләренә муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләреннән азат итүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү. Күрсәтелгән аренда түләүләреннән азат итү, әгәр аренда шартнамәсендә Әлмәт районының муниципаль казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәт, шулай ук күрсәтелгән эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен аннан файдалану максатларында чикләнмәгән һәм күрсәтелгән эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен тиешле мөлкәттән файдалануны раслый торган документлар булган очракта гамәлгә ашырыла;

б) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары- арендаторлар өчен 1 пунктның «а» пункты нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында әлеге карар үз көченә кергән көннән алып өч эш көне эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтына урнаштыру.

2. Әлеге карар нигезендә күрсәтелгән аренда түләүләреннән азат итү, Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага, әлеге карарның 1 пункты «а» пунктында каралган эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый торган җирләрне, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне арендага бирү шартнамәләре буенча узган чорда аренда түләүләре буенча башкарылмаган бурычлары булмаган арендаторларга карата гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль
районы Советының 2020 елның
13 маендагы 374 нче номерлы
карарына 2 нче кушымта

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына
Әлмәт районының муниципаль казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен кичектереп тору шартлары

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының башкарма комитетыны исеменнән эш итүче Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы Әлмәт муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне (алга таба - муниципаль мөлкәт) арендалау шартнамәләре буенча түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары-арендаторларның бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мөрәҗәгать иткән көннән алып җиде эш көне эчендә, Әлмәт районының муниципаль казнасын төзи торган, дәүләт милке чикләнмәгән җирләргә аренда түләүләрен кичектерүне күздә тоткан, муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча 2020 елның апрель - июнь айлары өчен, мондый арендаторларга кичектереп торылган аренда түләүләре срогы башлангач, 2021 елның январеннән дә да соңга калмыйча өстәмә килешүләр төзү;

б) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары- арендаторлар өчен 1 пунктның «а» пункты нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында әлеге карар үз көченә кергән көннән алып, өч эш көне эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштыру.

2. Әлеге карар нигезендә аренда түләүләрен кичектерү, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына-арендаторларга, аларның Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча узган чорда аренда түләүләре буенча Татарстан Республикасы территориясендә үтәлмәгән бурычлары булмаучыларга бирелә дип билгеләргә. Әлеге карарның 1 пунктының “а” пункты нигезендә төзелә торган өстәмә килешүләр 2020 елның апрель - июнь айлары өчен аренда түләвен кичектерүне һәм аны 2020, (яисә) 2021 елларда аренда шартнамәсендә каралган срокларда тигез өлешләр белән түләүне күздә тота, шулай ук аренда түләве, килешү шартнамәсе вакытыннан алда туктатылганда, бер мәртәбә түләнә торган суммага да кагыла .

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль
районы Советының 2020 елның
13 маендагы 374 нче номерлы
карарына 3 нче кушымта

Әлмәт районы муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләре кичектерү шартлары

1. Күчемсез мөлкәттән файдаланган өчен 2020 елда каралган аренда түләвен кичектерүнең әлеге шартлары Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан 2020 елда кадәр кабул ителгән «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Федераль законның 11 статьясы, Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимын кертү турындагы карар нигезендә төзелгән күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре, Россия икътисады тармакларында эшчәнлек алып баручы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары белән расланган (алга таба - аренда шартнамәсе, кичектерү) белән расланган яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә вәзгыятьнең начараюы шартларында зыян күрүче оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр булган арендаторларга карата кулланыла.

2. Күчемсез милеккә карата, торак биналардан тыш, кичектерү бирелә.

3. Кичектерү срогы 2020 елның 1 октябренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимын кертү көненнән башлап түбәндәге шартларда бирелә:

а) аренда түләве буенча бурыч 2021 елның 1 январеннән да иртәрәк булмыйча һәм 2023 елның 1 январеннән дә соңга калмыйча, айга бер тапкыр, күләме буенча аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан да артмаган тигез түләүләргә туры килергә тиеш;

б) кичектерү Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимының гамәлдә булу срогына тиешле чор өчен аренда түләве күләмендә һәм 2020 елның 1 октябренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы гамәлдә булу туктатылган көннән алып, тиешле чор өчен аренда түләвенең 50 проценты күләмендә бирелә;

в) арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын сакламау (шул исәптән мондый чаралар аренда килешүендә каралган очракларда) белән бәйле рәвештә, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки башка җаваплылык чаралары кулланылмый;

г) арендага бирүче тарафыннан кичектерү бирелүгә бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләрне билгеләү рөхсәт ителми;

д) кичектерү бирелә торган аренда түләвенең күләме, яклар килешүе буенча төшерелергә мөмкин;

е) әгәр аренда килешүендә арендатор тарафыннан коммуналь хезмәтләрдән файдаланган өчен түләүләрне һәм (яки) арендалана торган мөлкәтне карап тоту чыгымнарын аренда түләвенә кертү күздә тотылса, аренда түләвенең күрсәтелгән өлеше буенча кичектерү, Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы гамәлдә булган чор белән бәйле очраклардан тыш, бирелми.

4. 3 пунктта каралган кичектерү шартлары, мондый килешү төзү датасына бәйсез рәвештә кичектерү турында аренда шартнамәсенә өстәмә килешүләргә карата кулланыла.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов